РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 06 » 03 2025 ел №217

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башкарма
комитетының "Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы территориясендә
торак хезмәтләре күрсәткән өчен түләү
күләмен раслау турында"гы 28.12.2024 ел
№ 1241 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару очрагында торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен тиешле сыйфатта булмаган һәм (яки) билгеләнгән вакыттан артыграк тәнәфесләр белән үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында"гы 13.08.2006 елның № 491 санлы карары, Россия Төзелеш Министрлыгының 06.04.2018 ел, № 213/пр санлы «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик тәкъдимнәр раслау турында» боерыгы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2025 елның 30 гыйнварындагы 04-04/1575 санлы хатына бәйле рәвештә, шулай ук норматив хокукый актны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә торак хезмәтләре күрсәткән өчен түләү күләмен раслау турында»гы 28.12.2024 ел, № 1241 санлы карарына кушымтаны әлеге карарга

кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
______ 2025 ел № _______
санлы карарына кушымта

**2025 елга социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләренә һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләренә торак урыннан файдаланган өчен, торак урынны карап токкан өчен түләү күләмен раслау турында, торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелышта карар кабул итмәүчеләр өчен түләү күләме**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **2025 елга тариф (01.01.2025 - 30.06.2025)** | **2025 елга тариф (01.07.2025 - 31.12.2025)** |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Торак фонд белән идарә итү | сум/$м^2$ | 1,81 | 1,94 |
| Йорт яны территориясен җыештыру | сум/$м^2$ | 2,17 | 2,32 |
| Торак бинаны агымдагы ремонтлау | сум/$м^2$ | 4,16 | 4,46 |
| Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту: | | | |
| - суүткәргеч-канализация челтәрләре | сум/$м^2$ | 2,66 | 2,85 |
| - фасад һәм йорт эчендәге газ челтәрләре | сум/$м^2$ | 0,41 | 0,44 |
| - челтәрләрне электр белән тәэмин итү | сум/$м^2$ | 1,50 | 1,61 |
| Йорт эчендәге газ җиһазлары составына керүче газүткәргечләргә техник диагностика ясау эшләре (30 елдан өлкәнрәк)* | сум/$м^2$ | - | 0,31 |
| Йорт эчендәге вентканалларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | сум/$м^2$ | - | 0,17 |
| Дератизация (дезинсекция) | сум/$м^2$ | - | 0,26 |
| Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | сум/$м^2$ | - | 1,87 |

* газүткәргеч файдалануга тапшырылганнан соң 30 ел узган КФЙ өчен (түләү диагностикалау срогы башланганчы 12 ай эчендә исәпләнә)